**УКАЗ**
**ПРЕЗИДЕНТА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ПРЕЗИДЕНТЫ**
**УКАЗЫ**

**О проведении в Республике Татарстан Года спорта и здорового образа жизни**

В целях создания условий для укрепления здоровья населения, популяризации массовых видов спорта, пропаганды здорового образа жизни и физической культуры, профилактики асоциальных явлений в молодежной среде, приобщения различных категорий населения к регулярным занятиям спортом, обеспечения доступности спортивных сооружений **постановляю:**

1. Объявить 2009 год Годом спорта и здорового образа жизни в Республике Татарстан.

2. Возложить обязанности по подготовке и проведению Года спорта и здорового образа жизни в Республике Татарстан на Республиканский совет по вопросам благотворительной деятельности.

3. Кабинету Министров Республики Татарстан в месячный срок разработать с привлечением министерств и ведомств Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления, общественных объединений, иных заинтересованных организаций и представить на рассмотрение Президента Республики Татарстан план основных мероприятий по подготовке и проведению Года спорта и здорового образа жизни в Республике Татарстан с указанием объемов и источников их финансирования.

4. Предложить главам муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан, территориальным органам федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, общественным объединениям, предприятиям и учреждениям, благотворительным и иным организациям принять активное участие в подготовке и проведении Года спорта и здорового образа жизни в Республике Татарстан.

5. ОАО «Тамедиа», ОАО «Телерадиокомпания «Новый век»,

МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РТ
КАНЦЕЛЯРИЯ
Вх. № 7966
«21» 10 2008 г.

республиканским и местным средствам массовой информации обеспечить широкое освещение проведения Года спорта и здорового образа жизни в Республике Татарстан.

6. Настоящий Указ вступает в силу со дня его опубликования.

**Президент**
**Республики Татарстан** **М.Ш.Шаймиев**

Казань,Кремль
20 октября 2008 года

№ УП-528

**УКАЗ**
**ПРЕЗИДЕНТА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ПРЕЗИДЕНТЫ**
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында Спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше елын уздыру турында**

Халыкның сәламәтлеген ныгыту, масса төсендәге спорт төрләрен популярлаштыру, сәламәт яшәү рәвешен һәм физик культураны пропагандалау, яшьләр арасында асоциаль күренешләрне кисәтү, халыкның төрле категорияләрен спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү, спорт корылмаларының кереп йөрерлеген тәэмин итү максатларында **карар бирәм:**

1. 2009 елны Спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше елы дип игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасында Спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше елын әзерләү һәм уздыру функцияләрен Хәйрия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча республика советына йөкләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бер ай вакыт эчендә, Татарстан Республикасы министрлыкларын һәм ведомстволарын, башкарма хакимият федераль органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарын, җирле үзидарә органнарын, җәмәгать берләшмәләрен, кызыксыну белдергән башка оешмаларны җәлеп итеп, Татарстан Республикасында Спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше елын әзерләүнең һәм уздыруның төп чаралары планын, аларны финанслау күләмен һәм чыганакларын күрсәтеп, эшләргә һәм Татарстан Республикасы Президенты каравына тапшырырга.

4. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, җәмәгать берләшмәләренә, предприятиеләргә һәм учреждениеләргә, хәйрия оешмаларына һәм башка оешмаларга Татарстан Республикасында Спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше елын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. «Татмедиа» ачык акционер җәмгыятенә, «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционер җәмгыятенә, республика һәм

урындагы массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасында Спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше елын уздыруны киң яктыртырга.

6. Әлеге Указ аны бастырып чыгарган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **М.Ш. Шәймиев**

Казан,Кремль
2008 ел, 20 октябрь

№ ПУ-528